ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.03.2019 Олы Кайбыч авылы № 142

Балалар һәм яшьләрнең
ялын оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.03.2016нчы елның 31нче мартында чыккан 191нче номерлы «Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» карарын үтәү өчен, 2019нчы елның мәктәп каникуллары чорында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА :

1.Кушымта итеп бирелә торган түбәндәге документларны расларга:

- Кайбыч муниципаль районының 2019нчы елга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру программасын;
- Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча район ведомствоара Нигезләмәсен;
- Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссия составын;
- Кайбыч муниципаль районында Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында Нигезләмәне;
- белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьлар өчен гариза үрнәге;
- балалар сәламәтләндерү лагерьлары өчен гариза үрнәге.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы жирле үзидарә органнары, яшьләр, балалар ижтимагый оешмалары житәкчеләренә:

- 2019нчы елның 29 маена кадәр оешмаларны балаларның 2019нчы елның жәйге чорындагы ялына әзерләп бетерергә;
- балаларның 2019нчы елның жәйге чорындагы ялы оешмаларының материаль –техник базасын әзерләргә, аларны мөмкин булган элемтә чаралары белән тәэмин итәргә (телефон яки рация белән);
- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру системасын саклау чараларын күрергә;

тәэмин итәргә:

- чакырылыш комиссияләре тәкъдимнәре буенча һәм медицина күрсәткечләрен исәпкә алып, шул исәптән укучы балаларның каникул вакытларында ялын оештыруны гамәлгә ашыручы, мәгариф оешмалары

тарафыннан оештырылган лагерьларда армиягә чакырылу яшенә җитмәгән егетләрнең ялын оештыру буенча;

- балар өчен ял оешмаларында караучысыз калган балалар өчен , РФ ЭЭМның Кайбыч муниципаль районы буенча балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә һәм бүлекчәләрендә учетта торучы балалар өчен һичшиксез урын булдыру;

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге иң күп сандагы балаларның ялын оештыру өчен шартлар;

- эш бирүчеләр һәм урындагы бюджет чаралары хисабыннан 14 яшьтән 18яшькәчә балаларны каникуллардагы буш вакытында вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештыру;

- «Кайбыч муниципаль районы мәшгульлек Үзәге» ДКУ белән берлектә балигъ булмаганнарны шәһәр һәм авыл предприятие, учреждение, оешмаларына вакытлыча эшкә урнаштыруны;

- балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән санитар-эпидемиологик, хокук тәртибе, санитар-экологик һәм янгын куркынычсызлыгы иминлеге, балаларның суда ял иткәндәге иминлеге һәм ял итү урыннарында аларны сәламәтләндерү буенча чаралар комплексын эшләү һәм үткәрү;

- һәр смена ачылыр алдыннан балаларның ялын оештыруның аларның янгын иминлеге таләпләренә, санитар кагыйдәләргә, суда кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләренә, хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау торышы, торак корпусларның, туклану блокларының, лагерьны су белән тәэмин итү чыганакларының санитар торышына, мунча-кер юу комплексларының торышына, электр җиһазларының торышына, янгын автоматикасының, кешеләргә янгын турында хәбәр итү системасының, телефон элемтәсенең, янгын сүндерүнең беренчел чараларының булу-булмавы һәм төзеклегенә, персоналның янгын иминлеге кагыйдәләрен белүен тикшерүгә аерым игътибар биреп, ял итүчеләрнең иминлеге шартларына туры килүен тикшерү максатында комплекслы тикшерү оештыру;

- балаларның ял итү оешмасын аларның гамәлдәге санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килүен раслаучы дәүләт-санитар эпидемиологик күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән документлар булганда, шулай ук лагерьларның матди-техник торышын ныгытуга юнәлдерелгән, янгын иминлеге бозуларны бетерү буенча күрсәтмәләрне тулы күләмдә һәм санитария законнарын бозулар буенча күрсәтмәләрне үтәгәндә ачу;

- балаларның ял итү оешмаларының санитар кагыйдәләрне үтәве һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләр уздыруга билгеләнгән тәртиптә аккредитация алган лабораторияләр белән килешүләр төзеп, санитар-эпидемиягә каршы (кисәтү) чарараларны үтәү;

- урман техник чаралар уздыру (кыска булып үсүче агачларны, корыган ботакларны, куакларны кисү, яшь үсентеләрне кисү, үләннәрне чабу, корысорыны һәм балаларның ял итү оешмалары территориясеннән чүп-чарны чыгару), ялны оештыру буенча бөтен кампания дәвамында һәм кирәк булганда коры-сорыны һәм чүп-чарны чыгару лагерь тирәли 500 метрлы радиуста талпанга һәм бөҗәкләргә каршы эшкәртү үткәрү;

- барлык корылмаларда дератизацион эшкәртүләр уздырыру, шул исәптән файдаланылмый торган, ачык территориядә, ял итү оешмасы тирәли 500 метр радиуста лагерьлар ачылганчы 30-40 көн алдан барьер булдырырга һәм аларны ачканчы 7 көн алдан һәм аларны консервациялэгәндә, ә сменалар арасында һәр дератизация эшкәртүеннән соң 30 көн саен нәтиҗәлелек контроле уздырып үткәрү;

- балаларның ял итү оешмалары территориясендә алар ачылганчы 14 көн алдан аның тирәли 50 метрлы зонада талпанга каршы эшкәртү уздыру, шулай ук энтомологик күрсәткечләр булганда, сменалар арасында;

- балаларның коллектив ял итүен оештыручылар балалар коллективларын республикадан читкә җибәрү турындагы планлаштырылган сроклар турында Татарстан Республикасы территориясенә аеруча куркыныч инфекцияләр кертүне, төркемле авырулар барлыкка килүне кисәтү максатында китәргә өч тәүлек кала Татарстан Республикасы буенча кулланучылар хокукын яклау һәм кешеләрнең иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсенә хәбәр итү;

- тимер юл, авиация, автомобиль юллары буйлап (юлда өч сәгатьтән артыграк булганда) һәм су транспортында ташу буенча санитар-эпидемиологик таләпләрне үтәү;

- ял итү оешмаларына эшкә урнашучы (эшләүче) затларның педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә Россия Федерациясенең Хезмәт кодексының 331нче, 351.1 нче маддәләрендә каралган каршылыклар булу-булмауга закон нигезендә алдан тикшерүләр уздыру оештыру;

- балаларны ташуны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 декабрендә чыккан "Балаларны автобуслар белән ташуны оештыру Кагыйдәләрен раслау турында"гы 1177нче Карары белән расланган балаларны автобуслар белән ташуны оештыру Кагыйдәләре нигезендә оештыру.

Оештырырга:

- талпан энцефалитын, боррелиозны һәм бөер синдромы белән геморрагик бизгәк авыруларын кисәтү максатында биналарга һәм территорияләргә (шул исәптән файдаланылмаучыларга да) әлеге эшләрне башкарырга хокукы булган аккредитация узган оешмалар белән муниципаль контрактлар (килешүләр) төзеп, дымлы профилактик дезинфекция, десинсекция һәм дератизацияләр үткәрү;

- янгын-техник минимум программалар буенча балаларнын ял итү оешма-ларының житәкче-педагогик составын укыту һәм барлык хезмәткәрләрне билгеләнгән тәртиптә гигиеник әзерләү;

- белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьлар өчен әти-әниләр түләү күләмен Татарстан Республикасында балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүгә киткән норматив финанс чыгымнарның 15 процентыннан да ким булмаганча итеп билгеләү.

3. "Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУнә:

- 2019 нчы елнын 1нче июненә кадәр белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларның, хезмәт һәм ял лагерьларының материаль –техник базасын тәэмин итәргә;

- белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларда, беренче чиратта, авыр тормыш хәлләрендә калган, ятим балалар, хәрби хезмәт үтүче, кораллы конфликтларда катнашкан һәм аларга якынайтылган гаиләләрдән булган балаларның ялын оештырырга, шул исәптән түләүсез;

- район белем бирү оешмаларында барлык спорт заллары һәм спорт мәйданнарының эшен тәэмин итәргә;

-янгын-техник минимум программалар буенча балаларның ял итү оешмаларының җитәкче-педагогик составын укыту һәм барлык хезмәткәрләрне билгеләнгән тәртиптә гигиеник әзерләүне тәэмин итәргә;

- 2019 нчы елның җәйге чорында район белем бирү оешмаларында балалар белән туристик –туган якны өйрәнү эшен дәвам итәргә;

- Әлеге Карар белән раслана торган 2019нчы елга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру программасы нигезендә, «Кайбыч муниципаль районы мәшгульлек Үзәге» ДКУ белән берлектә балигъ булмаганнарны шәһәр һәм авыл предприятие, учреждение, оешмаларына вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырырга;

- укуда, балалар иҗатында, спортта ирешкән уңышлары һәм балалар һәм яшьләр хәрәкәтендә актив катнашкан балаларны республика сменаларына җибәрергә;

- белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларда вакытлыча өстәмә белем бирү оешмалары ачылуны тәэмин итәргә;

- белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларга эшкә җибәрелүче мәгариф системасы хезмәткәрләрнең төп эш урыны буенча хезмәт хакын сакларга.

4. Милекнең нинди төре белән эшләвенә карамастан, предприятие һәм оешма житәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- канунчылык нигезендә предприятие һәм оешма акчалары хисабына балаларның ялын өлешләп финанслауны оештыруда катнашырга;

- балигъ булмаганнарның куркынычсыз эш шартларын булдырырга һәм аларның хезмәте белән куллануны хезмәт канунчылыгы нигезендә оештырырга.

5. "Кайбыч үзәк район хастаханәсе" сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесенә тәкъдим итәргә:

- белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларында медицина хезмәте күрсәтүне урындагы ФАП медицина хезмәткәрләре исәбеннән оештырырга;

- балигъ булмаганнарның укудан буш вакытларында һәм каникуллар чорында аларны вакытлыча эшкә урнаштырганда, шулай ук балалар белән ял итү оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең бушлай медицина караулары узуларын тәэмин итәргә;

- ял итү оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналны сезонлы караулар кысаларында бушлай флюорография тикшеренүен тәэмин итәргә;

- барлык төр сәламәтләндерү лагерьларында балигъ булмаганнар арасында алкоголизм, наркомания һәм токсикомания профилактикасы буенча эшне көчәйтергә;

- коллектив ял оештырганда баларны һичшиксез медицина хезмәткәре озатуны тәэмин итәргә;

- оештыручылар соравы буенча лагерьларны медицина кадрлары белән комплектлаштырырга;

- балигъ булмаганнарның укудан буш вакытларында һәм каникуллар чорында аларны вакытлыча эшкә урнаштырганда бушлай медицина караулары узуларын тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасында 2019нчы елда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчадан түләүләр алмыйча, ял итү оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналны сезонлы карауларны тәэмин итәргә;

- медицина күрсәтмәләре һәм тыюлары буенча дүрт яшьтән унҗиде яшькә кадәрге балаларны «Детская» (озатуларсыз) яки «Мать и дитя» (ата-аналарның берсе яки законлы вәкиле озатуында) юлламалары буенча санитар дәвалауны оештырырга.

6. «Татарстан Республикасы бенча Яшел Үзән районы һәм Яшел Үзән шәһәре (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенә түләү алмыйча түбәндәгеләрне уздыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

- ял итү оешмаларының гамәлдәге санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә тәңгәл килүенә санитар-эпидемиологик экспертиза;

- ял итү оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналны профилактик медицина караулары һәм гигиеник укытулар, аларны ачар алдыннан лаборатор-инструменталь тикшеренүләр, шулай ук гельминтозларга ( тизәктә паразитлар, лямбийләр булу-булмауга һ.б.анализ), эчәк инфекциясе барлыкка китерүне йөртүгә, корсак тифына канны серологик тикшерүләр;

- 2019нчы елның җәйге чорында укудан буш вакытта һәм каникуллар чорында балигъ булмаганнарны вакытлыча мәшгульлеккә рәсмиләштергәндә медицина караулары.

7. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Апас, Кайбыч муниципаль районнары буенча идарәсенә ял итү оешмаларында янгын иминлеге таләпләрен үтәүгә күзәтчелек итүне һәм яшьләр һәм балаларның күпләп ял итү урыннарында техник тикшереп чыгуны тәэмин итәргә.

8. Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт бүлегенә:

- авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын оештырырга, шул исәптән:

- җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән ким булган гаиләләрдәге балаларның;

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларның (тормышы яки саулыгы өчен куркынычбулган, я булмаса балалар тәрбиясе һәм яшәү шартларына җавап бирми торган мохиттәге балалар);

- социаль тернәкләндерүгә мохтаж булган балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүче балаларның;

- социаль тернәкләндерүгә мохтаж булган балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүчеләр, социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балалар белән алкоголизм, наркомания һәм токсикомания профилактикасы буенча эшләп барырга.

9. «Кайбыч муниципаль районы мәшгульлек Үзәге» ДКУнә тәкъдим итәргә:

- 14 яшьтән 18 яшькә кадәр булган балигъ булмаган балаларның шәһәр һәм авыл предприятие, учреждение, оешмаларына каникуллар вакытында буш араларында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырырга;

- беренче чиратта балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясендә һәм бүлекчәләрендә хисапта торучыларны вакытлыча эш белән тәэмин итәргә.

10. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт бүлегенә:

- Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча Министрлыгы системасы шәһәр яны ял һәм сәламәтләндерү лагерьларына бирелгән путёвкалар нигезендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештырырга;

-2019нчы елның җәйге чорында һәрторак пунктта массакүләм спорт чаралары үткәрүне тәэмин итәргә;

- Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге белән берлектә көндезге ял лагерьларында алкоголизм, наркомания һәм токсикомания профилактикасы буенча, сәламәт яшәүрәвеше пропагандасы буенча чаралар оештырырга;

- Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы карамагындагы ял итү оешмаларына, юлламалар алган балалар турында, ял һәм сәламәтләндерү лагерьларында ял итүчеләр турында мәгълүмат бирү буенча оператив һәм гомумиләштерүче мәгълүматлар бирү буенча эшне тәэмин итәргә.

- яшүсмерләрнең хәрби-патриотик тәрбиясенә юнәлдерелгән чаралар оештырырга.

11. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә:

- белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларда клуб хезмәткәрләре көче белән массакүләм мәдәни чаралар оештырырга.

12. Россия Эчке эшләр бүлегенең Кайбыч районы буенча бүлегенә:

закон нигезендә балаларны лагерьларга оештырылган алып баруны һәм алып кайтуны башкаручы транспорт чараларын озата баруны тәэмин итәргә;

- “Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУ белән берлектә балалар юл-транспорт травматизмын кисәтү һәм каникуллар чорында балаларның урамда булуы куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны тормышка ашырырга ;

- каникуллар чорында җинаятьләр кылу һәм караучысыз калу профилактикасы буенча чаралар күрергә;

-балаларны лагерьга алып бару һәм алып кайту вакытында бушлай транспорт чараларын озата баруны оештыруны тәэмин итәргә.

13. "Буа электр челтәре челтәрле компаниясе " ААҖнең Кайбыч филиалы РЭЧнә белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларда туктаусыз лектроэнергия килүне тәэмин итәргә.

14."Таттелеком" ААҖнең Буа электр элемтәсе филиалына караган Кайбыч район электр элемтәсе бүлегенә белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларда туктаусыз телефон элемтәсе булдыруны тәкъдим итәргә.

15. Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнары Башлыкларына 2019нчы елның 1 июненә кадәр 2019нчы елның җәйге чорына балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләрен карарга һәм канунчылык нигезендә һәр укучыны колачлый торган ял чаралары белән тәэмин итәргә.

16. “Татмедиа” ААҖ филиалы “Кайбыч таңнары” район газетасына 2019 ел җәйге чорында җәйге сәламәт-ләндерү кампаниясенә әзерләнү һәм аны үткәрү эшчәнлеге турында даими рәвештә яктыртуны тәкъдим итәргә.

17. Кайбыч муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карар белән расланган 2019 елда Кайбыч муниципаль районында “2019 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру программасын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016нчы елның 31нче мартында кабул ителгән 191нче номерлы “Балалар һәм яшьләр ялын оештыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субсидияләр бүлү” Карары нигезендә бирелә торган субсидияләр хисабына финанслауны тәэмин итәргә.

18. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

19. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ш. Бикбовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Н. Макаров**

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019нчы елның
«28»нче мартында чыккан 142нче
номерлы карарына Кушымта №1

Кайбыч муниципаль районының
2019нчы елга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру
**ПРОГРАММАСЫ**

1. Программа паспорты

| | |
|---|---|
| программа атамасы | Кайбыч муниципаль районының 2019нчы елга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру Программасы (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказчы | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшкәртүчеләре | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт бүлеге , " Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ |
| Программаның төп үтәүчеләре | Кайбыч муниципаль районының финанс-бюджет палатасы;<br>Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге;<br>Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт бүлеге;<br>"Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ;<br>Кайбыч муниципаль районының "Экология, Культура, Мәгариф" ӨББ МБУ Өстәмә белем бирү Үзәге,<br>Татарстан Республикасы социаль яклау Министрлыгының Кайбыч муниципаль районы буенча социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>«Кайбыч муниципаль районы мәшгульлек Үзәге» ДКУ (килешү буенча);<br>Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссиясе (по согласованию);<br>Россиянең Татарстан буенча Апас һәм Кайбыч муниципаль районнарында НЭ һәм ПЭ буенча районара надзор бүлеге |
| Программа максаты һәм бурычлары | Балачакны саклау, яшьләр һәм балаларның каникуллар чорында ялын, сәламәтләнүен һәм мәшгульлеген түэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;<br>яшьләр һәм балаларның ялы, сәламәлеге һәм мәшгульлеге өчен шартлар тудыру;<br>уңышлы булмаган балаларның тормышын яхшырту һәм |

| | |
|---|---|
| | проблемаларын хәл итү;<br>ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, инвалид балалар, шулай ук хроник авырулардан интегүче балалрга дәүләт ярдәме күрсәтү;<br>яшьләр һәм балалар ялының, яшьләр һәм балалар туризмы һәм спортының төрле формаларын үстерү;<br>яшьләр һәм балалар ялы инфраструктурасын саклау;<br>балалар авырулары һәм инвалидлыгы профилактикасы;<br>авыр тормыш хәлендә калган балаларның җәмгыять белән интеграциясен саклау һәм аларны эффектив комплекслы социаль саклауны формалаштыру;<br>балигъ булмаганнар арасында сукбайлык һәм җинаять кылулар профилактикасы;<br>ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның алып үстерүче гаиләләрдә тәрбияләнүенә ярдәм итүче шартлар булдыру;<br>ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны тәрбиягә алган гаиләләргә дәүләт ярдәме |
| Программаны тормышка ашыру срогы һәм этаплары | 2019нчы ел–2020нче елның марты |
| программаны финанслау | ТР бюджеты –**2091013,06** сум, әти-әниләр взносы - **316812,89** сум предприятиеләр взнослары 0,00 сум |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларда сменалар оештыру<br>2. Хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыру<br>3. Коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмаларда ( дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) шәһәр читендәге лагерьларда профильле сменалар оештыру<br>4. дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен шәһәр читендәге лагерьларда профильле сменалар оештыру.<br>5. Балигъ булмаганнарны вактылыча эш белән тәэмин итү |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗә бәяләү индикаторлары ) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 яшьтән 17 яшькәчә балаларның гомуми санының 50 процентыннан да ким булмаган санын каникуллар вакытында төрле ял һәм сәламәтләндерү формалары белән тәэмин итү .<br>Ял сыйфатын үстерү савыгу дәрәҗәсен барлык программа чаралары кысаларында 80 процанттан да ким булмаганча тәэмин итү. |

**1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру Программасы 2019 нчы елда юнәлдерелгән проблема характеристикасы.**

Җәйге каникуллар табигый савыктыру факторларының күпкырлылыгы белән уникаль. Балалар сәламәтлеген ныгытуның аеруча нәтиҗәле һәм туры килә торган массакүләм формасы - гомуми һәм санатор типтагы ял-сәламәтләндерү учреждениеләре. Балар ялын оештыруга төрле юнәлештәге һәм тематикадагы шәһәр яны лагерьлары, санатор лагерьлар, көндезге лагерьлар, палаталы лагерьлар керә. Алар барысы да үсеп килүче буынның җәйге чорга гына түгел, башка периодларга да саулыгы ныгытуга китерәләр.

Балалар ял-сәламәтләндерү лагерьларын саклау барлык дәрәҗәдәге җитәкчеләрнең дә ныклы игътибарында булырга тиеш. Балалар һәм яшьләрнең, бигрәк тә ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм һәм авыр тормыш шартларында калган балалар өчен ял итү һәм яшьтәшләре белән иркле аралашу мөмкинлеге булдыруга максималь уңайлы шартлар тудыру дәүләтнең балачакны саклау өлкәсендә беренчел бурычы булып тора.

Ял, сәламәтләндерү һәм мәшгульлекне оештыруга максатчан килү конкрет периодка балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерүне оешкан формаларда планлаштыру һәм үткәрүгә нигезләнә.

Балалар һәм яшьләрнең әлеге учреждениеләрдә булуының программа-методик һәм укыту-тәрбияви тәэмин ителеше күпкә яхшырды; алдагы еллар белән чагыштырганда психолог –педагогик, физкультура-спорт, медицина һәм башка белгечләрнең квалификация дәрәҗәләре үсте.

2015нче елда билгеләнгән төп тенденция әлеге Программа кысаларында: массакүләм туры килә торган; яңа территорияләр үзләштерү, ял һәм савыктыру чикләрен киңәйтү (ягъни эш механизмы үзләрендә ял итү учреждениеләре булмаган муниципаль берәмлекләр балаларны башка районнарга (регионнарга) җибәрә торган итеп төзелгән.

Балаларны ялның оештырылган формалары белән тәэмин итүне санауның максатчан индикаторларын исәпләгәндә 7 яшьтән 17 яшькәчә балаларның гомуми саны исәпкә алына.

Баларның сәламәтлеге социаль –икътисадый , демографик һәм медик –биологик факторлары катлаулы бәйләнешенең интеграль күрсәткече буларак формалаша, алар арасында экологик мохитнең начараюы, тиешенчә булмаган һәм балансланмаган туклану , укучыларны мәктәптә, гаиләдә укыту һәм тәрбияләүнең шартлары һәм технологиясе, гаиләнең икътисадый иминлеге киму һәм җәмгыятьтәге социаль киеренкелек белән бәйле стресс йогынтылар, начар гадәтләр таралу мөхим булып тора. Ел саен балалр, яшүсмерләр һәм яшьләр тормышы сыйфатын үстерү буенча максатчан системалы эш алып барыла. Әлеге Программаның төп максаты - балачакны саклау, яшьләр һәм балаларның каникуллар чорында ялын, сәламәтләнүен һәм мәшгульлеген түэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру.

Алдагы елларда Программаны тормышка ашыруның уңай нәтиҗәләре булуга карамасан, балаларның эшчәнлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт дәрәҗәсендә чишелергә тиешле күп проблемалар калып килә.

**2019 нчы елга расланган норматив күләмнәр нигезендә әлеге программа чикләрендә үткәрелүче**

**ЧАРАЛАР**

| №п\п | ЧАРА АТАМАСЫ | Үткәрү вакыты | Кеше саны | Оештыруга җаваплы (үтәүче) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Балаларның һәм яшьләрнең белем бирү оешмаларында көндезге вакыт өчен оештырыла торган лагерьларында ялын оештыру | Июнь-август<br>гынвар | 360<br>300 | "Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ |
| 2 | Балаларның һәм яшьләрнең ТР шәһәр яны лагерьларында ялын оештыру | Июнь-август | 35 | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт бүлеге |
| 3 | Балаларның һәм яшьләрнең ял һәм хезмәт лагерьларында ялын оештыру | июнь | 100 | "Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ |
| 4 | Җәйге каникуллар чорында балигъ булмаганнарның (мәктәп укучыларынын) вакытлыча мәшгульлеген оештыру | Июнь-август | 100 | «Кайбыч муниципаль районы мәшгульлек Үзәге» ДКУ |
| | барысы | | | |

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019нчы елның «28»нче мартында чыккан 142нче номерлы карарына Кушымта №2

# БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘР ЕЛЫ ОЕШТЫРУНЫҢ РАЙОН ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Балалар һәм яшьләрнең елын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе (алга таба - Комиссия) Кайбыч муниципаль районы балалры һәм яшьләренең елын координацияләү һәм оештыру максатында оештырылган.
2. Комиссияне рәис җитәкли. Урынбасар һәм сәркатибе бар. Комиссия составына Кайбыч районы Башкарма комитетының структур бүлекләре, министрлык һәм ведомстволарның Кайбыч районында урнашкан территориаль бүлекчәләре, башка оешма һәм учреждение вәкилләре керә. Комиссиянең персональ составы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.
3. Комиссия үз эшчәнлегендә канунчылык һәм әлеге Нигезләмәгәтаяна.

4. Комиссиянең төп бурычлары:

- Кайбыч районы Башкарма комитетының бүлекләре, шулай ук Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт органнары, фондлар, предприятиеләр, оешмалар, яшьләр һәм балаларның елын, мәшгульлеген , аларны сәламәтләндерүне оештыру белән шөгыльләнүче мәгариф оешмалары эшен координацияләү;

- Кайбыч районы Башкарма комитетының бүлекләре, шулай ук Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт органнары, фондлар, предприятиеләр, оешмалар, яшьләр һәм балаларның елын, мәшгульлеген , аларны сәламәтләндерүне оештыру белән шөгыльләнүче мәгариф оешмалары эшен анализлау, аларның җитәкчеләренең хисапларын тыңлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар чыгару, аларның үтәлешен тикшерү;

- Кайбыч муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең елын оештыруны финанслау мәсьәләләрен карау;

- Кайбыч муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең елын оештыру Программасын тормышка ашыруны контрольләү.

5. Комиссиянең хокуклары:

- Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә балалар һәм яшьләрнең елын оештыру мәсьәләләре буенча эшләнгән тәкъдимнәр кертү;

- балалар һәм яшьләрнең елын оештыруда катнашучы Кайбыч районы Башкарма комитетының бүлекләре, шулай ук Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт органнары, фондлар, предприятиеләр, оешмалардан канунчылык нигезендә аның аәкаләтләренә карый торгант документлар, мәгълүматлар, материаллар сорау;

- балалар һәм яшьләрнең елын оештыру буенча норматив хокукый актлар һәм документларның үтәлешен контрольләү, тикшерү.

6. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү белән күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмә комиссия сәркатибе белән алып барыла һәм Комиссия рәисе белән имзалана.

7.Комиссия утырышлары кирәк булган саен үтә. Көн тәртибен һәм үткәрү тәртибен Комиссия рәисе билгели.

8. Комиссия утырышлары анда барлык әгъзаларның 2/3се катнашса, хокукый дип санала.

Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче
Д.Ә. Бәдертдинова

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019нчы елның «28»нче мартында чыккан 142нче номерлы карарына Кушымта №3

## БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘР ЕЛЫ ОЕШТЫРУНЫҢ РАЙОН ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

**Комиссия рәисе:**

Бикбова Ф.Ш. - Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары

**Комиссия рәисе урынбасарлары:**

Лотфуллина З.Ф. - Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт бүлеге начальнигы

**Комиссия сәркатибе:**

Шоркина А.А. – "Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ тәрбия эшләре буенча методисты

**Комиссия әгъзалары:**

Хәмидуллин И.И. – "Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ начальнигы

Камалиева Ч. Г. - Кайбыч муниципаль районында хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы бүлеге җитәкчесе (килешү буенча)

Камалеева Э.Р - «Кайбыч муниципаль районы мәшгульлек Үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча)

Михайлова Л.Г. - Кайбыч муниципаль районы Финанс –бюджет палатасы җитәкчесе

Сафин Р.М. - Яшел Үзән, Югары Ослан, Кама Тамагы, Кайбыч районнарында ТР (Татарстан) буенча Роспотребнадзор территориаль идарә бүлеге җитәкчесе урынбасары (килешү буенча)

Сафина А.Г. - баш белгеч - Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның зокукларын яклау комиссиясенең җаваплы сәркатибе

Әбләзова.Р.Р.- Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе

Сөнгәтуллина Л.М. - “Татмедиа” ААҖ филиалы “Кайбыч таңнары” район газетасына директоры - баш мөхәррире (килешү буенча)

Вәлиев И.И.- Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Апас, Кайбыч муниципаль районнары буенча районара бүлек җитәкчесе (килешү буенча)

Кәлимуллина Ф.Н. - Россиянең Кайбыч районы буенча ЭЭМ ның балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәсе өлкән инспекторы (килешү буенча)

Сафиуллина Г.И. - "Кайбыч үзәк район хастаханәсе" ССДАУ баш табибы

Баһавиева Н.А.- Кайбыч муниципаль районы “Экология, Мәдәният, Мәгариф” мәктәптән тыш эшләр Үзәге” МБ ӨББУ директоры

Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче Д.Ә. Бәдертдинова

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019нчы елның
«28»нче мартында чыккан 142нче
номерлы карарына Кушымта №4

**Кайбыч муниципаль районында**
**Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Кайбыч муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру механизмын һәм Кайбыч муниципаль районының дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының, районда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы дәүләти һәм дәүләти булмаган учреждениеләрнең, оешмаларның һәм гражданнарның зара хезмәттәшлеге тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыручы вәкаләтле орган булып Кайбыч муниципаль районы балалар һәм яшьләрнең ялын оештыручы Район ведомствоара комиссиясе тора. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыручы Район ведомствоара комиссиясе эш тәртибе һәм составы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

1.3. Әлеге Нигезләмә кысаларында балалар һәм яшьләр ялы өчен шәхеснең белем бирү һәм иҗат потенциалын үстерүне, саулыгын саклау һәм ныгытуны, авыруларны профилактикалау, организмны чыныктыруны, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләре формалаштыру, балигъ булмаганнарның күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау, иҗтимагый файдалы һәм җитештерү хезмәте, физик культура, спорт, туризм белән шөгыльләнүне, өлешчә яки тулысынча каникул вакытында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабына финанслана торган шартлар һәм чаралар комплексы аңлашыла .

2. Балалар һәм яшьләрнен ял итү, савыгу һәм мәшгульлек формалары.

2.1. Кайбыч муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

шәһәр яны ял лагерында смена;
шәһәр яны ял лагерында профиль смена;
белем бирү оешмасы оештырган көндезге яллы лагерьда смена;
ял һәм хезмәт лагеренда смена;
санатор-курорт оешмаларында смена.

2.2. Шәһәр читендәге ял лагерында смена-каникуллар вакытында балалар һәм тәрбияләнүчеләр белән стационар базасында үткәрелә торган ял һәм белем бирү эшчәнлеге формасы.

2.3.Шәһәр яны ял лагерында профильле смена ул- иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы белән ял итү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы, каникуллар вакытында укучылар һәм тәрбияләнүчеләр белән тәүлек буе стационар базасында үткәрелә.

2.4. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге яллы лагерьда смена - ул каникуллар вакытында белем бирү оешмалары базасында укучыларнын көндезге вакытта булуы

һәм аларның туклануын мәҗбүри оештыру белән үткәреләә торган ял һәм белем бирү эшчәнлеге формасы.

2.5. Хезмәт һәм ял лагеренда смена - каникуллар вакытында иҗтимагый файдалы хезмәт оештыру белән ял итү формасы, ул күбесенчә гомуми белем бирү оешмалары базасында көндезге вакытта булдырыла һәм туклану белән тәэмин ителә.

2.6. Санатор –курорт оешмасындагы смена – ул укучы һәм тәрбияләнүчеләрнең санатор –курорт оешмасында тәүлек әйләнәсе булуы һәм реабилитацион һәм (яки) тергезү дәвалануы бирә торган чаралар үткәрелә торган савыгу эшчәнлеге формасы.

2.7. Вакытлыча эшкә урнашу ул - хезмәт һәм укыту эшчәнлегенең балигъ булмаганнарны вакы тлыча хезмәт белән тәэмин итә торган, аларның гаиләләренә каникуллар чорында социаль ярдәм күрсәтү максатында оештырыла торган ял формасы.

2.8. Смена үткәрү сроклары оештыручы тарафыннан билгеләнә.

2.9.Балалар лагерьларында отрядлар балаларның мавыгулары һәм яшеннән чыгып комплектлаша. Отрядлар саны шәһәр яны ял лагерында эш режимын оештыруга Санитар –эпидемиологик таләпләр куйган нормативларга карап билгеләнә.

3.Балалар һәм яшьләрнең ял кампанияләрендә катнашучылар.

3.1. Ял кампанияләрендә Кайбыч муниципаль районы территориясендә даими яшәүче 7-17 яшьлек балалар һәм 30 яшькә кадәрге яшьләр катнаша ала.

3.2. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге категория балалар һәм яшьләр арасында гамәлгә ашырыла:

гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары;

һөнәри белем бирү учреждениеләре студентлары;

муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары;

коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмаларда эшләүче хезмәткәрләрнең балалары;

иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр;

девиант тотышлы балалар;

хроник авырулы балалар , шул исәптән әти-әнисенең берсе белән;

эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрендә һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә профилактик исәптә торучы балалар.

4. Балалар һәм яшьләр ялын оештыручы булып Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, "Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ се тора.

5.Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслау тәртибе.

5.1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыручы оешмаларны финанслау түбәндәге чыганаклардан алына:

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

предприятие һәм оешмалар акчалары;

ата-аналар акчасы.

5.2. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслауда өлешләп катнашу күләме шәһәр читендәге лагерьда профильле смена өчен тиешле финанс елына балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга норматив чыгымнарның 85 процентын, шәһәр читендәге лагерьда смена өчен - коммерция һәм

коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләре балалары өчен (федераль буйсынудагы оешмаларны да кертеп) тиешле финанс елына балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга норматив чыгымнарның 42,5 процентын тәшкил итә.

6. Ял өчен ата-аналар түли торган акча күләмен
билгеләү тәртибе.

6.1. Сәламәтләндерү учреждениеләрендә ял өчен ата-аналар түләве күләме балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга финанс чыгымнары нормативыннан 15 проценттан да ким булмаган күләмдә билгеләнә, тик путевканың ял төрләренә карап, фактик бәясеннән 50 проценттан да артмый.

6.2.Оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең үзкыйммәтенә тигез чыгымнарны чагылдыручы юлламаның бәясе билгеләнә. Әгәр норматив чыгымнар реаль чыгымнарга туры килми икән, юлламаның факттагы бәясе һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар өлеше арасындагы аерма ата-аналар (яки законлы вәкилләр), оешмалар тарафыннан түләнә.

6.3. Сәламәтләндерү учреждениеләрендә ял өчен ата-аналар түләве түбәндәгеләрдән алынмый:

Авыр тормыш хәлендә калган балалардан;

Ятим балалардан, балалар йортлары һәм мәктәп- интернатта тәрбияләнүчеләрдән;

хроник авырулы балалардан, шул исәптән аны озатучы бер ата-анадан;

балигъ булмаганнар буенча эшләр комиссиясендә исәптә торучылардан, девиан тотышлы балалардан;

республика, бөтенрәсәй, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләреннән һәм призерларыннан.

7. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге яллы лагерьда
балаларның ял сменасын оештыру тәртибе

7.1. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге яллы лагерьга белем бирү оешмалары укучылары ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризалары нигезендә җибәрелә.

7.2. Ата-аналарның гаризасы "Татарстан Республикасы Кайбыч районы мәгариф бүлеге" МКУ тарафыннан расланган форма буенча бала укый торган белем бирү оешмасына бирелә.

7.3. Белем бирү оешмасы ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасы нигезендә көндезге яллы лагерьга җибәрелә торган балалар исемлеген төзи һәм аны Кайбыч муниципаль районы мәгариф бүлегенә тапшыра . Ирекле исемлектә тәбәндәгеләр күрсәтелә:

Баланың фамилиясе, исеме, әтисе исеме,

Гариза биргән ата-ананың (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисе исеме;

Баланың туу датасы, җенесе;

Ата-ананың (законлы вәкилнең) эш урыны;

Бала укый торган белем бирү йорты атамасы;

Бала укый торган сыйныф .

"Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ исемлек нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы балаларының җыелма исемлеген һәм белем бирү оешмасы оештырган көндезге ял лагерьларында аларның ялын оештыру планын төзи.

7.4. Мәгариф оешмасы оештырган көндезге ял лагерьларында балаларнын ялын оештыру планы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тиешле финанс елына

расланган лагерьларда балалар һәм яшьләр ялын оештыруга хезмәт курсәтү күләмнәре нормативлары чикләрендә төзелә һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

лагерьлар оештырылачак белем бирү оешмаларының исемнәре;

лагерьларда белем бирү оешмалары буенча оештырылган урыннар саны;

белем бирү оешмалары киселешендә оештырылган лагерьларда сменалар саны һәм аларнын дәвамлылыгы;

балаларны лагерьлар оештырылачак белем бирү оешмалары буенча бүлү.

7.5. Мәгариф оешмасы оештырган көндезге ял лагерьларында балаларның ялын оештыру планы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының сәламәтләндерү кампанияләре өчен аерым карары белән раслана.

7.6. Өч көнлек срокта Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына ялны оештыруда катнашучыларның саны турында мәгълүмат җибәрә.

7.7. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге ай саен, 25 числога кадәр, ял итеп кайткан балаларның санын һәм балалар ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына ял оештыру буенча мониторинг җибәрә.

7.8. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге яллы лагерьларда ял итү вакыты чыкканнан соң җиде көн эчендә "Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресларына лагерьларда башкарылган эшләр турында мәгълүмат җибәрә.

## 8. Мәгариф оешмасы оештырган көндезге хезмәт һәм ял лагерьларында ял сменасын оештыру тәртибе

8.1. Көндезге хезмәт һәм ял лагерьларына гомуми белем биру оешмалары укучылары аларны иҗтимагый-файдалы хезмәткә җәлеп итү максаты белән җибәрелә.

8.2. Гомуми белем бирү оешмасы ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризалары нигезендә хезмәт һәм ял лагерьларына җибәрелә торган балалар исемлеген төзи, аны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә тапшыра. Ирекле исемлектә түбәндәгеләр күрсәтелә:

Баланың фамилиясе, исеме, әтисе исеме,

Баланың туу датасы, җенесе;

Ата-ананың (законлы вәкилнен) эш урыны;

Бала укый торган белем бирү йорты атамасы;

Бала укый торган сыйныф.

"Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ исемлек нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы балаларының җыелма исемлеген һәм белем бирү оешмасы оештырган көндезге хезмәт һәм ял лагерьларында аларның ялын оештыру планын төзи.

8.3. Хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын оештыру планы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан тиешле финанс елына расланган Кайбыч муниципаль районы лагерьларында балалар һәм яшьләр ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативлары чикләрендә формалаштырыла һәм үз эченә түбәндәгеләрне ала:

Хезмәт һәм ял лагерьлары оештырылачак белем бирү йортлары атамалары;

Белем бирү оешмалары буенча хезмәт һәм ял лагерьларында иҗтимагый файдалы хезмәткә тартылыган кеше саны.

8.4. Мәгариф оешмасы оештырган көндезге хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын оештыру планы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының сәламәтләндерү кампанияләре өчен аерым карары белән раслана.
8.5. Өч көнлек срокта Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына ялны оештыруда катнашучыларның саны турында мәгълүмат жибәрә.
8.6. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетынын яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге ай саен, 25 числога кадәр, ял итеп кайткан балаларның санын һәм балалар ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына ял оештыру буенча мониторинг жибәрә.
8.7. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге хезмәт һәм ял "Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресларына лагерьларда башкарылган эшләр турында мәгълүмат жибәрә.

9. Шәһәр яны лагерьларында балаларның ялын оештыру тәртибе

9.1.Шәһәр яны лагерьларына муниципаль яки дәүләт оешмасы (алга таба — оешмалар) хезмәткәре булган ата-аналарның балалары (яки законлы вәкилләрнең) Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлегенә бирелгән гаризасы нигезендә жибәрелә. Гариза Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты раслаган формада бирелә.
9.2. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге шәһәр яны лагерьларына баручы балаларның исемлеген төзи.
9.3. Якынча исемлектә түбәндәгеләр күрсәтелә:

учреждение атамасы;
Баланың фамилиясе, исеме, әтисе исеме;
Гариза биргән ата-ананың (законлы вәкилнең ) фамилиясе, исеме, әтисе исеме;
Баланың туу датасы, җенесе;
Бала укый торган белем бирү йорты атамасы;
Бала укый торган сыйныф.

9.4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге, муниципаль җирлеге Башкарма комитеты якынча исемлек нигезендә шәһәр яны лагерьларында балаларның ялын оештыру планын төзи.
9.5. Оешма хезмәткәрләре балаларының ял итү планы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.
9.6. Шәһәр яны лагерьларында балаларның җәйге ял кампаниясе тәмамланганнан соң Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына җиде көн эчендә оешма хезмәткәрләре балаларының ялын оештыру турында хисап җибәрә.

10. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешма хезмәткәрләре балаларының (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) ялын оештыру тәртибе.

10.1. Әти-әнисенең берсе Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешма хезмәткәре балаларының (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) булган гомуми белем бирү оешмасы укучысы әти-әнисенең берсе үзе эшли торган оешманың бухгалтер бүлегенә биргән гаризасы нигезендә шәһәр яны ял лагерена җибәрелә. Гариза Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты раслаган формада бирелә.

10.2. Оешманың бухгалтер һәм хисап бүлеге шәһәр яны лагерьларына баручы балаларның исемлеген төзи һәм әлеге якынча исемлекне Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлегенә тапшыра.

10.3. Якынча исемлектә түбәндәгеләр күрсәтелә:

оешма атамасы;

Баланың фамилиясе, исеме, әтисе исеме;

Гариза биргән ата-ананың (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисе исеме;

Баланың туу датасы, җенесе;

Бала укый торган белем бирү йорты атамасы;

Бала укый торган сыйныф.

10.4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге, муниципаль җирлеге Башкарма комитеты якынча исемлек нигезендә шәһәр яны лагерьларында ял итәчәк балаларның исемлеген төзи.

10.5. Оешманың бухгалтер һәм хисап бүлеге шәһәр яны лагерьларына баручы балаларның исемлеген Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлегенә җибәргәндә, шәһәр яны лагерьларында ял путевкасы норматив бәясенең 42,5 процент күләмендә өлешчә түләүне оешма үз өстенә алуы хакында турында оешманың җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантияле хат та җибәрә.

10.6. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге, муниципаль җирлеге Башкарма комитеты якынча исемлек нигезендә шәһәр яны лагерьларына баручы оешма хезмәткәрләре балаларының якынча исемлеген төзи.

10.7. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты якынча исемлек нигезендә бу балаларның шәһәр яны лагерьларында ял планын төзи.

10.8. Планга түбәндәгеләр керә: оешма атамасы, муниципаль бирем нигезендә балалар җибәреләчәк муниципаль шәһәр яны лагерьларында урыннар һәм сменалар саны; 2005нче елның 21 июлендә 94-ФЗ номерлы чыккан «Дәүләт муниципаль кирәге өчен хезмәт күрсәтү, эш башкару, товар китерү заказлары урнаштыру» Федераль законы нигезендә оештырылучы ачык конкурс нигезендә сатып алына торган юлламалар саны.

10.9. Шәһәр яны лагерьларына баручы оешма хезмәткәрләре балаларының ялын оештыру планы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

10.10. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетынын яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына ял итәргә киткән балалар саны турында мәгълүмат бирә.

10.11. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге ай саен, 25 числога кадәр, ял итеп кайткан балаларның санын һәм балалар ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына ял оештыру буенча мониторинг җибәрә.

10.12. Шәһәр яны лагерьларында ял итү вакыты чыкканнан соң җиде көн эчендә Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетынын яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына оешма балалары өчен үткәрелгән савыктыру кампаниясе турында мәгълүмат бирә.

11. Уртача кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк булган, социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүчеләр, социаль куркыныч хәлдәге гаилә балаларының ялын оештыру тәртибе.

11.1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетынын яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге начальнигы Лотфуллина З.Ф. җаваплы булып тора һәм җан башына туры килгән кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк булган, социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүчеләр, социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдән булган балаларның ата-аналарының (законлы вәкиле) юллама сорап язган гаризаларын җыя.

11.2. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге,гаризалар нигезендә исемлек төзи һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына җибәрә.

11.3. Кайбыч муниципаль районында хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау Министрлыгы бүлеге ай саен Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетынын яшьләр сәясәте һәм спорт бүлегенә җан башына туры килгән кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган, айлык пособие билгеләнгән балалар, социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүчеләр, социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдән булган балалар реестрын бирә.

11.4 Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетынын яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге Кайбыч муниципаль районында хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау Министрлыгы бүлеге биргән мәгълүматлар нигезендә айлык пособие билгеләнгән балалар, социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүчеләр, социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдән булган балалар исемлегенрасл ый.

11.5. Җан башына туры килгән кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган, айлык пособие билгеләнгән балалар, социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүчеләр, социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдән булган балалар белән эшләү планы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан формалаштырыла һәм үз эченә түбәндәгеләрне ала: республика лагерьлары атамасы, әлеге категориягә караган балалар җибәрелә торган лагерьлардагы урын һәм смена саны, канунчылык нигезендә оештырылучы ачык конкурсларда сатып алына торган юлламалар саны.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019нчы елның «28»нче мартында чыккан 142нче номерлы карарына Кушымта №5

**Гариза үрнәге**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы________________________
гомуми белем бирү мәктәбе » МБББМ директоры
_____________________________________________________________
(директорның Ф.И. әтисенең исеме)

_____________________________________________________________
(ата-ананың, законлы вәкилнең Ф.И. әтисенең исеме)

гариза.

Мин, эти-әнисе , законлы вәкиленең Ф.И. әтисенең исеме ___ сыйныф укучысы Ф.И. әтисенең исеме эти-әнисе , законлы вәкиле Сездән баламны 2019нчы елның ___ ___нан _______ на кадәр мәктәп яны көндезге ял лагерына алуыгызны сорыйм.

__________
Дата

________
имза

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019нчы елның «28»нче мартында чыккан 142нче номерлы карарына Кушымта №6

Оешма (учреждение) җитәкчесенә
*Әнисенең Ф.И. әтисенең исеме*

______________________________

______________________________

*Әнисенең эш урыны* ______________________

______________________________

*Әтисенең Ф.И. әтисенең исеме* __________

______________________________

______________________________

Әтисенең эш урыны

______________________________

*Законлы вәкиленең Ф.И. әтисенең исеме*

______________________________

***индексын күрсәтеп (теркәлү урыны ) буенча өй адресы*** (

______________________________

__________________ *һәм* ***чынлыкта яшәү урыны буенча*** )

______________________________

______________________________

*Контакт е телефоны (өй, эш, кәрәзле)*

______________________________

**Гариза.**

**Минем балам** ______________________________

(баланың Ф. И. әтисенең исеме тулысынча )

______________________________

__________________ туган (көне, ае, елы), ________, женесе (ир бала, кыз бала) туу турында таныклык (паспорт) серия ____________ № ______________________________ бирелү датасы ______________________________,

бала укый торган белем бирү оешмасы ____________ ____________, сыйныфы ______________ ,

__________________ лагерына ______нче _ сменага җибәрүегезне сорыйм.

Бала турында өстәмә мәгълүматлар (**кирәгенең астына сызарга**):

14) ятим,
15) әти-әнисез калган,
16) күпбалалы гаиләдән,
17) тулы булмаган гаиләдән,
18) качаклар һәм күчеп китәргә мәҗбүр булучылар гаиләсеннән,
19) хәрби конфликтларда катнашкан хәрбиләр гаиләсеннән,
20) балигъ булмаганнар эше буенча комиссиядә исәптә торучы.

**Гаризага беркетелә:**

*- баланың укуы урыныннан белешмә,*
*- баланың туу турында таныклыгы якипаспорты копиясе,*
*- мәктәптән белешмә,*
*-- әти-әниләр паспортлары копияләре,*
*- әти-әниләрнең эш урыныннан белешмә.*

«__» ____________ 2019ел

Имза ________________